
Кадошкино районы Большие Поляны топ мәктәбе укучылары очен укытучылары, укучыларнын әниләре белән бергә, «Ажаган» уены vткәргәннәр.
Укучыларны патриотик тәр-бияләv, шәхесне һәрьяклап форма-лаштырунын нәтижәле чарасы буларак спорт туризмын арттыру максатларында сыйныф житәкчеләре, әти-әниләре белән бергә, укучылар очен урманга, Большая Поляна авылы аркылы аккан Исса елгасы ярындагы урманчыкка сәяхәт-поход оештыралар.      «Поход - яшvсмерләрнен гармонияле vсеше очен бик яхшы чара, ул спорт һәм ял формасында тормышка ашырыла. Сәяхәт табигатьне кvрергә һәм тоярга момкинлек бирә. Үзендә зур танып белv потенциалы, әйләнә-тирә мохитне актив танып белv момкинлеге бар. Болар барысы да кvзаллауны кинәйтv генә тvгел, ә белемгә, ачышларга кызыксынуны кочәйтv, кызыксынуны vстерv, туган якка мәхәббәт тәрбияләv», - ди мәктәп директоры кинәшчесе Зәйнәб Хосәен кызы Кильдеева.
Походта балалар ял итv урыннарын тозекләндерvдә рәхәтләнеп ярдәм иткәннәр. Сәламәт һәм кvнелле ял итv тәмле ризык кебек vк моһим. Поход вакытында хәрби-патриотик «Ажаган» уены уздырыла. Чарада катнашучылар алдан ук хәрби жырлар әзерләп ойрәнгән. Һәр команда осталыкларын ярышларнын торле формаларында кvрсәткән. Капитаннар арасында ярыш оештырылган. Аннары командалар житезлектә һәм тапкырлыкта коч сынашкан. Теоретик белемен практик эшчәнлектә куллану командаларга жинv очен корәштә ярдәм иткән һәм һәрвакыттагыча дуслык жингән.

**Н.ХӘЛИЛ**